**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2024 елның «11» мартыннан № 102

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «2020 - 2025 елларга Яңа Чишмә муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында» 2020 елның 06 июнендәге 144 номерлы карары расланган «2020 - 2025 елларга Яңа Чишмә муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2023 елның 29 декабрендәге 2386 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «2020 - 2025 елларга Яңа Чишмә муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында» 2020 елның 06 июнендәге 144 номерлы карары расланган «2020 - 2025 елларга Яңа Чишмә муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

II бүлектә «II.Программа чаралары системасы» «социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба - ЕГИССО) торак шартларын яхшырту өчен яшь гаиләләргә бирелә торган социаль түләүләр турында мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртип һәм күләм нигезендә һәм ЕГИССО операторы билгеләгән форматлар нигезендә урнаштыруны тәэмин итү» сүзләрен «социаль өлкәдә бердәм цифрлы платформада торак шартларын яхшырту өчен яшь гаиләләргә бирелә торган социаль түләүләр турында мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәте

билгеләгән тәртип һәм күләм нигезендә һәм ЕЦП операторы билгеләгән форматлар нигезендә урнаштыруны тәэмин итү.». сүзләренә алыштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http//novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов